| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| «8» октябрь 2019 ел | № 146 |

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану соравы буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Норма авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Норма авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану соравы буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2019 елның 19 сентябрендәге 144 номерлы Норма авыл җирлеге Советының карары, «Норма авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану соравы буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2019 елның 19 сентябрендәге 15 номерлы Норма авыл җирлеге башкарма комитетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясендә 2019 елның 01 декабренә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану соравы буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«Норма авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган һәм референдумда тавыш бирергә хокукы булган гражданнарга 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул җыелган акчаларның түбәндә күрсәтелгән урындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына Сез ризамы:

- Кариле авылында: Дружба, Г.Тукай урамнарында асфальт-бетон катламлы юлны ремонтлау; Т.Миннуллин, Төзүчеләр, Г.Исхакый урамнарында юлга вак таш катламы җәйдерү; Лесная, Овражная урамнарында вак ташлы туфрак катламы җәйдерү; зират коймасын төзекләндерү;

- Норма авылында: Ленина урамындагы юлга вак таш катламы җәйдерү; Гагарин урамында вак таш катламлы юлны ремонтлау; «Нурислам» чишмәсенә баручы юлга вак таш катламы җәйдерү; М.Җәлил, М.Гафури урамнарындагы су коеларын ремонтлау; М.Җәлил урамында җәяүлеләр баскычы урнаштыру; М.Җәлил урамындагы балалар мәйданчыгы өчен коймалар сатып алу һәм урнаштыру; Ленин, М.Садри урамнарында ясалма тигезсезлекләр урнаштыру һәм юл билгеләре кую;

- Чапшар авылында: Х.Туфан, Ш.Усманов урамнарында юлларны өлешчә ремонтлау һәм асфальт-бетон катламы җәйдерү; зиратка баручы юлга вак таш катламы җәйдерү;

- Кили авылында: Г.Тукай урамындагы юлга вак таш катламы җәйдерү; зиратка баручы юлга вак таш катламы җәйдерү; уен мәйданчыгы эшләтү;

- Пүскән авылында: уен мәйданчыгы эшләтү; су белән тәэмин итү проектын эшләтү;

- Нормабаш авылында: Г.Ибраһимов һәм Н.Баян урамнарын тоташтыручы күперне ремонтлау.

**ӘЙЕ** **ЮК**».

3. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны экономия барлыкка килгән очракта, Норма авыл җирлеге Советы карары нигезендә янга калдырылган акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында һәм Татарстан Республикасының pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, Норма авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Норма авыл
җирлеге башлыгы Р.Н.Шарипҗанов